# БӘЙРӘМ БЕЛӘН СЕЗНЕ, АСЫЛ ЗАТЛАР!


СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

7 МАРТ, 1997ел. ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 26 (8038) | Бәясе билгеләнгәнчә.


## Ул - йортыбыз тоткасы



Иртәгә - хатын - кыз бәйрәме. Кемнәр генә, ничек кенә инкарь итәргә тырышмасын, ул бәйрәм хатын - кызларыбызга бик тә кирәк. Ул көнне алар елмаюларны да, күңел җылысын да күбрәк тоялар, куанычлары да мулрак була. Үзенең багланышы белән балаларыбыз турында, йорт, гаилә, табыннарыбыз хакында кайгыртырга чакырылган хатын - кызларыбызга бу мәшәкатьле заманда бик авырга килә. Шуңа да аларга карата күңелләрегездә изгелек - яхшылыкны да кызганмагыз, җылы, ягымлы сүзләрегезне дә ешрак әйтергә тырышыгыз. Һәм бер бүген генә дә түгел.

Н.АЗИЗОВ фотосы.

## Күңел күтәрелеп кайттым

**Халыкара хатын - кызлар көне алдыннан Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев чакыруы буенча Казанга җөмһүриятебезнең төрле өлкәләрендә эшләүче гүзәл хатын - кызларыбызның зур бер төркеме җыелды. Барлык районнардан килгән күпсанлы хатын - кызларыбыз Казан милли - мәдәни үзәгендә республика җитәкчеләре белән очраштылар. Анда безнең районнан да вәкилләр бар иде. Шуларның берсе - район суды рәисе Галина Николаевна ГРИШОВА безнең хәбәрчебез белән әңгәмәсендә очрашудан алган тәэсирләре белән уртаклашты.**

Бу мәртәбәле очрашуга безнең районнан ике кешегә - «Кондырча» күмәк хуҗалыгы ферма мөдире Сания Шакирҗановна Таҗиевага һәм миңа чакыру килде. Очрашудан алган тәэсирләрне бер генә сүз белән әйтеп бетерергә һич мөмкин түгел. Очрашу узган милли - мәдәни үзәктәге тантаналылык та, шул кадәр күп сандагы кунакларның һәрберсенә аермаенча игътибарлылык та, гаять югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү дә (чәй өстәлләре артында утырдык бит) - һәммәсе таң калырлык булды. Президентыбызның без - хатын - кызларга карата шундый матур һәм җылы сүзләр табып, тормышның барлык өлкәләрендә - эштә дә, гаиләдә дә йөкнең авырын тартып баручы гүзәл затларга җәмгыятьтә үз җилкәләренә алган зур җаваплылыкны намус кушканча, җиренә җиткереп башкарулары өчен әйткән ихлас рәхмәтен ишетү беребезне дә битараф калдырмагандыр. Ә очрашуны алып баручы - Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республика хатын - кызлары оешмасы рәисе Зилә Вәлиева бу очрашуга чакырылганнар арасында хезмәтләре белән бөтен республикага танылган бик күп данлыклы хатын - кызларыбыз белән таныштырып, аларның һәркайсы турында җылы сүзләр әйтүе шулай ук дулкынландыргыч булды. Нинди генә авыр тармакларда эшләми безнең хатын - кызларыбыз, нинди генә җаваплы вазифалар башкармыйлар. Тик тормышта кем генә булсалар да, җитәкчеме, гади эшчеме, хатын - кыз барыбер иң элек хатын - кыз булып кала һәм игътибарга, ягымлы карашка, җылы сүзгә чын күңеленнән сөенә. Менә бу истәлекле очрашу, елына бер тапкыр гына булса да, анда чакырылган һәркемнең күңелендә хисләр дә уяткандыр, матур хатирәләр дә калдыргандыр, бу авыр заманда тормышка, яшәүгә омтылышын да арттыргандыр дип уйлыйм. Шәхсән үзем аннан бик канәгать калып, күңелем булып кайттым. Һәр көне төрле мәшәкатьләр белән тулы булган, нинди генә гайрәт чигәрлек хәлләрдә дә үзендә кешелеклелек сыйфатларыңны саклап калырга, түзем һәм сабыр булырга көч табарга мәҗбүр итә торган бу тормышта күңел күтәрерлек шундый чаралар да бик кирәк.

## ЯЗ БЕЛӘН, 8 МАРТ БЕЛӘН!

**Кадерле хатын - кызлар! Язның беренче көннәре белән безгә бу якты, кояшлы бәйрәм дә килә, һәм без, традиция буенча, сезгә тугъры йөрәгегез, кайгыртучан кулларыгыз өчен рәхмәт сүзләре әйтәбез. Миңа сез, игелекле аналар, хатыннар, сеңелләр - апалар, кызлар һәм әбиләр, данлыклы хезмәткәрләр һәм гаилә учагын саклаучыларны котлау ихлас канәгатьлек китерә. Бу бәйрәмнең сезгә көтелмәгән шатлыклар, елмаю һәм җан җылылыгы китерүен телисе килә.**

**Бүген безнең җәмгыять икътисади, сәяси реформалар кичергәндә, проблемаларның иң авыр йөге безнең хатын - кызларыбыз, йорт хуҗабикәләре җилкәсенә төшүен аерым билгеләргә кирәк. Шуңа да бүген һәм иртәгә район хакимияте гаиләнең матди терәген тәэмин итү, социаль сакланышын саклауны яхшыртуда үзенең төп бурычын күрә. Халыкның тормыш - көнкүрешен яхшырту, авылда реформалар үткәрү, газлаштыру проблемаларын хәл итүне тизләтү, хезмәт хакы һәм пенсияләр белән тәэмин итүне активлаштыру - безнең гомуми бурычыбыз булып тора. Һәм без әлеге мәсьәләләрне практик хәл итү буенча мөмкин булганнарның барысын да эшләрбез.**

**Кадерле хатын - кызлар! Ватаныбыз тарихы битләрен күңелдән барлап, ышаныч белән әйтеп була: хатын - кызлар аңа байтак ачык һәм истә калырлык битләр яздылар. Бөек Ватан сугышының дәһшәтле елларында йөз меңләгән хатын - кыз кулларына корал тотып, Ватанны саклады - лар, миллионлаган хатын - кызлар тылда авырлыклар кичерделәр. Ә ирләре фронттан кайтмаган толларны санап бетерү мөмкинмени? Чын күңелдән хатын - кыз ветераннарны бәйрәм белән котлап, аларга саулык - сәламәтлек һәм тыныч картлык, җан шифасы һәм җылылык телисе килә.**

**Сезнең безнең җәмгыятьтә тоткан ролегезне сүзләр белән әйтеп бирү бик авыр, хәтта мөмкин түгел. Сезнең акыл һәм йөрәгегез өчен рәхмәт. Безнең өстәлебездәге икмәк, эшләрегез һәм фикерләрегез, тормышчан түземлелегегез өчен рәхмәт. Сезнең иң яхшы хыялларыгыз тормышка ашсын!**

**Бәйрәм белән, хөрмәтле хатын - кызлар!**

**Ф.СИБАГАТУЛЛИН,**
**халык депутатларының район Советы рәисе, хакимият башлыгы.**

## ЭШЕНДӘ ДӘ ҖИТЕЗ, ӨЕНДӘ ДӘ...

Алиевлар терлекчелектә тулы бер династия эшлиләр. Агалы - энеле Минхатип белән Минвахит, аларның хатыннары Минҗиһан белән Нурдидә, өлкән Алиевларның кызы Гөлинә. Һәркайсы тырыш, эшчән. Бүгенге язмамның герое «Чирмешән» КХАсының алдынгы савучыларының берсе, килендәшләрнең өлкәне Минҗиһан апа. Ул гомерен терлекчелеккә багышлаган кеше. Балачагы Фома авылында үтә аның. Әнисе, апасы белән генә үскән кызга кечкенәдән тормышның әчесен дә, төчесен дә күрергә туры килә. Башта ике ел сарыклар карый, эшенең нечкәлекләренә төшенә. Аннан биш еллап фермада сыерлар сава. 1969 елда исәкыр, дала ягы авылында туып үскән кыз урман - әрәмәлеге өстенә аварга торган Кәкре Атауга - Алиевлар гаиләсенә килен булып төшә. Ишле гаиләдә дә, авылда да үз итәләр кызны. Минҗиһан фермага, яраткан эшенә килә. Менә егерме җиде ел инде ул сыерлар сава. Савымчы хезмәте, билгеле булганча, җиңелләрдән түгел. Арка - билләр дә, кул - аяклар да сызлый торгандыр. Гомер эзсез узмый. Шул еллар эчендә биш бала табып үстерергә дә, өлкәннәрен башлы - күзле итеп, әби белән бабай булырга да өлгерә алар. Минхатип абый белән Минҗиһан апа кайнатасы белән кайнанасын да, үз әнисен дә картлык көннәрендә кадер - хөрмәттә яшәтә. Һәркайсын олылап соңгы юлга озата. Йорт - кураларыда таза - пык Алиевларның. Күп итеп мал - туар асрыйлар. Гаиләсендә дә, эшендә дә җитез, өлгер Минҗиһан апа. Авырлыкларны да җиңел кичерә белә ул. Йөзеннән ягымлылык китми үзенең. Савучының тырышлыгын җитәкчеләр дә күрә, бәяли. Минҗиһан апа эшләү дәверендә кыйммәтле бүләкләр дә, «Коммунистик хезмәт ударниты» билгеләрен дә ала. Мактау грамоталары да күп аның. Районда дүртмеңчеләр хәрәкәте җәелгән чорда алар арасында Минҗиһан Алиева да була. Хәзер дә сынатмый. Узган елда үзе караган һәр сыердан уртача 3436 шар килограмм сөт савып алган. Икенче елын фермада сыерлар савучы кызы Гөлинәгә дә үз осталыгын, үз тәҗрибәсен өйрәтә.

Ж.ШАКИРОВ,
хәбәрче.

## Белми калмагыз!

**Язның беренче бәйрәме - 8 нче Март уңаеннан норлатлыларны 7 март көнне район культура йортында**

### «Чәчәк бүләк итик гүзәл затка»

***дип исемләнгән шоу - концертка чакырабыз. Аның программасына гүзәл затларыбызны җылы котлаулар, районның иң яхшы үзешчәннәре көче белән әзерләнгән концерт, төрле миниатюралар кертелгән. Шунда ук тынлы оркестр астында биюләр каралган.***

***Бәйрәм тамашасы 18.00 сәгатьтә башланачак.***

**9 март көнне шәһәрнең үзәк мәйданында**

### «Масленица»

***массакүләм халык күңел ачуы оештырыла. Иртәнге 9дан 9.30 га кадәр махсус киенгән яшьләр бизәлгән атларда халыкны бәйрәмгә чакырып йөриячәкләр. 9.30дан 10га кадәр атларда балаларны урам әйләндерәчәкләр. Сәгать 10да күңел ачу башлана. Анда кышны озату театрлаштырылган тамашасы, зур концерт, һәртөрле конкурслар, уеннар, аттракционнар, ярышлар булачак. Халыкка сәүдә, җәмәгать туклануы службалары хезмәт күрсәтәчәк. Иң мөһиме, анда сезне кайнар чәй белән коймак көтә.***

**Тамашаларга рәхим итегез!**

# Бу дөньяда Сездән бөегрәк

## Назлы туташ, Затлы ханымнар!

*Хатын-кызның иңнәренә дөнья*
*Башын салган шушы заманда*
*Яшәү чыганагы-иң гүзәл зат*
*Хатын-кыз бит әле һаман да*

*Куш:*
*Хатын-кызлар,гүзәл хатын-кызлар,*
*Назлы туташ,затлы ханымнар,*
*Янәшәдә сез булганда гына*
*Ышанычлы безнең адымнар.*

*Бар дөньясын буйсындырмак булып*
*Көч-гайрәтне чәчеп торсак та*
*Хатын-кызлар,гүзәл хатын-кызлар,*
*Мәхәббәткә мохтаҗ ир-ат та*
*Кушымта, шул ук.*

*Ир-егетнең гаярь көче җитмәс*
*Хатын-кыз ул-серле бер тылсым.*
*Сөю-сәгадәттән ләззәт тоеп,*
*Бар хатын-кыз бәхетле булсын!*

*Куш:*
*Хатын-кызлар, гүзәл хатын -кызлар,*
*Назлы туташ,затлы ханымнар,*
*Янәшәдә сез булганда гына*
*Ышанычлы безнең адымнар.*

***Фәүзия Мөхәммәтова***

## *Хезмәтенә куана*



Ачык йөзле, сабыр холыклы, тыйнак Сәлимә Мәҗитовна сөт - май комбинатында күптәннән үз кеше. Шулай булмый ни: 20 еллап гомерен шушы заводка багышлаган бит ул. Шунда гади эшче булып эшкә килде, читтән торып Димитровград сөт техникумын тәмамлады һәм менә 12 ел инде смена мастеры вазифасын башкара. Үз эшен нечкәлекләренә кадәр белүе өстенә, Сәлимә Мәҗитовна кешеләр белән эшлекле җылы мөнәсәбәт урнаштыру, аны саклый белүе белән хөрмәт яулады. Гел хатын - кызлардан торган коллектив өчен шундый җитәкче булу, үзара анлашып эшләү - зур бәхет ул. Бу яктан коллектив бер отса, хезмәтеннән куаныч, иптәшләрендә сердәш тапкан Сәлимә Мәҗитовна икеләтә бәхетле саный үзен.

**Рәсемдә: Норлат сөт - май заводы смена мастеры С.М.Хөсәенова.**

## Тынгысыз хезмәттә

Армас беләкле, талмас йөрәкле тынгысыз Рәшидә Сәмигуллинаны авылда аерата бер ихтирам белән хөрмәт итәләр. Моңа нигез дә бар. Шушы авылга читтән килеп тормышка чыкты Рәшидә. Иптәше Йосыф белән бергәләп өч бала үстерделәр. Авыл халкы аның 19 яшеннән сылу гәүдәле, сөйкемле яшь ханым чагында товарлыклы - сөтчелек фермасына килүен дә хәтерли. Үтә бер үҗәтлек, тырышлык белән эшкә өйрәнде, сабырлык, хезмәт белән тәҗрибә туплады. Хәзер инде аның фермада эш стажы 28 ел исәпләнә. Рәшидә Нурмиевна күрсәткечләрен дә елдан - ел яхшырта бара. Узган ел малларның һәрберсеннән 3674әр килограмм сөт савып алды ул.

- Бу - алдагы ел күрсәткеченнән 664 килограммга артыграк,- ди ферма мөдире Марс Габбасович Кутузов Рәшидәне мактап. Рәшидә Сәмигуллина беренче класслы машина белән саву мастеры. Ул районда гына түгел, заманында республикада да унган дигән данын раслаган савучы. Ул чакта яхшы күрсәткечләргә ирешеп, «Васильево» санаториена путевка белән бүләкләнгән иде. Ә савучы кешегә, үзегез беләсез, ялы да, дәвасы да бик тансык.

Рәшидә Нурмиевна хәзер дә Хафизов исемендәге КХАның Кормыш фермасында эшен дәвам итә. Халыкара хатын - кызлар көне - 8 мартта да ул эш урынында - фермада булачак. Нишлисең, маллар өчен ял да, бәйрәм дә юк шул. Рәшидә Нурмиевна Сәмигуллина шундый тынгысыз хезмәтне сайлавына зарланмый - үкенми вахтасын дәвам итә, өендә исә ул - мөлаем хатын - кыз, кайгыртучан ана, тугъры хатын.

**Т.ДЕРБЫШЕВ.**
**Хәбәрче.**

## Котлыйбыз



Кычытканлы авылында яшәүче кадерле әниебез **Әминә Минап кызы Мингалимованы** туган көне - 60 еллыгы белән кайнар котлыйбыз.

Әни бит ул - өйнең яме,
Ә тормышта - олы бәр терәк.
Озак яшә, сәламәт бул
Син бит, әни, безгә бик кирәк.

**Кызлары, уллары, киленнәре, кияүләре, оныклары.**



*Кәкре Атау авылында яшәүче кадерле кыз туганыбыз* ***Шәмсегаян Хәбибулла кызы*** *һәм аның тормыш иптәше* ***Фоат Солтангали улы Галәветдиновларны*** *көмеш туйлары белән чын күңелдән бездән кайнар котлыйбыз. Аларның һәр икесенә таза сәламәтлек, гаилә бәхете, озын гомер телибез.*

***Иң изге теләкләр белән Шәрәповлар һәм Вильдановлар гаиләсе.***

## Мәңгелек моң

Бөтен дөнья серле
әкият кебек
Сихри тынлык
яна таралган
Кышкы хистән
иркәләнеп урман
Мәңге бетмәс моңга
уралган.
Ак йолдызлар ява
салмак кына
Очып килеп
керә кочакка.
Чук күлмәкле
чыршы көнләшүдән
Ыңгырашып куя
шул чакта.
Кулларымны сузам,
тотам карны -
Иркәләнеп
эри кулымда.
Сак - сак кына йөрим,
Йолдыз кебек
кар энҗеләр ята
юлымда.
Ак йолдызлар
хыялланып күктән
Ашыгып - ашыгып
җиргә явалар,
Кышкы моңнан
юатырга теләп,
Битләремә кунып
яналар.

**Дания САТДАРОВА.**

## КҮҢЕЛЕНӘ КҮРӘ КӨН КҮРӘ

*Чулпан авылында яшәүче* ***Рушания Сәлих кызы Хәниевага*** *60 яшь тула.*

*Кадерле әниебез! Сине туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз. Киләчәк тормышыңда бетмәс - төкәнмәс бәхет, ныклы сәламәтлек, кояштай озын гомер, күз карасыдай үстергән 3 балаңның игелеген күреп, әтиебез белән кайгы - хәсрәтсез, тигезлек белән яшәвеңне телибез.*

*Гел шатланып яшә, әни, хәсрәт күрмә,*
*Тыныч булсын һәрчак күңелең.*
*Бәрәкәтле матур тормыш сиңа!*
*Кояшларга тиңе гомернең.*

***Тормыш иптәше, балалары һәм килен - кияүләре.***



Була бит шундый кешеләр: алар теләсә нинди кешеләр арасында тиз арада «үз»гә әвереләләр, һәрчак игътибар үзәгендә булалар. Рушания апа да шундый. Аны беренче тапкыр күреп, аралашуга ук бу хатын - кызны үтәли күргән кебек буласың. Гадилеге, ачык күңеллелеге белән беренче көннән үк якын танышыңа әверелә ул. Ә холкындагы тотрыклылыгы исә еллар үтү белән дә үзгәрми, сакмый.

Рушаниянең биографиясе бик гади. Фомада Салих Гафуров гаиләсендә дүрт малай арасында бердәнбер кыз булып үсә ул. Мәктәптән соң Бөгелмәдәге медицина училищесын тәмамлый һәм юллама буенча Чулпанга эшкә җибәрелә. Шунда Йосыфхан атлы егет белән гаилә коралар. Ике кыз, бер ул үстерәләр. Рушания исә 43 ел берөзлексез Чулпан авылы халкына медицина хезмәте күрсәтә. Кыскача биографиясе шундый аның. Ә шушы гади нәрсәләр артында күпме гомер тора бит.

... Рушания Чулпанга эшкә билгеләнүен бүгенгедәй яхшы хәтерли. Тирә - якка белемле, шул ук вакытта таләпчәнлеге белән даны таралган табиб Березина битләре ал янып торучы чибәр, чая Рушанияне ике куллап эшкә алды. Сүзгә кесәсенә керми, һәр нәрсәдән кызык табып, чын күңелдән көлә белгән кызны күпләргә тәтеми торган игътибар белән чорнап ала өлкән табиб. Яшь белгечне бу хис канатландыра, күпне белергә, яхшы эшләргә омтыла ул. Участок шифаханәсеннән фельдшерлык пунктына мөдир итеп күчерелгәндә тиз арада тупланган бай хезмәт тәҗрибәсе, халык арасындагы абруена карап фикер йөртәләр районда гылар. Шулай дүрт дистә елдан артык хезмәте хезмәт кенәгәсендәге бер язуга сыйды да куйды.

- Кешедән артык эшләдем дип санамыйм. Бурычым шундый иде бит,- ди Р.Ханиева тыйнак итеп бу турыда. Анысы шулай. Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек аның гомерлек юлдашы булды. Шәфкать тутасының бирегә беренче эшкә килгән көненнән шаһит чулпанлылар Рушаниягә карап гаҗәпләнәләр.

- Син бүген дә шул көндәге кебек үк күр күңелле,- диләр танышлары еллар үтүгә дә карамастан төз гәүдәле, ал янып торучы битле Рушаниягә сокланып,- тьфу, тьфу, күз генә тимәсен...

Югыйсә, анысының да булуы бар. Әле күптән түгел, гомерендә булмаганча чирләп, Йошкар - Олага катлаулы операциягә җыенганын белгәч, авылның яше - карты изге теләктә калганнар иде.

- Әлегәчә күңеленә күрә көнеңне бирә килә иде ходай, терелеп кайта күр, берүк,- дигәннәр иде. Савыгып, аякка басуына авылдашларының да теләкләре ярдәм иткәндер, мөгаен. Әнә, хәзер йөгерә - чаба үзе шуларга ярдәмгә ашыга. Хәер, гомере буе шундый булды инде: кемгә дә булса ярдәм кирәк булганда көн - төн белән исәпләшмәде: беренче кирәк - ярак медицина җиһазларын тотып, кышкы салкында, ачы буранда, көзге - язгы пычракларда булсын - ярдәмгә ашыга. Кайчак җиңел кием кигән килеш авыру өчен машина табыштырырга, еш очракта авыруны Норлатка кадәр дә озата барырга, яисә сырхауны шифаханәгә илтеп җиткергәнче үк хәлиткеч карар да кабул итәргә туры килә аңа. Шуңа да дөньясын онытып тынычлап йоклаган төне дә сирәк булды аның үз гомерендә.

( Ахыры 4 нче биттә).

# һәм гүзәлрәк бары ... Сез генә!

*Янәшәбездә хатын - кыз*

## АҢА НАСЫЙП ҺӨНӘР

Әүвәл бераз хыялланып алыйк. Әйтик, ул кайчандыр кием теккән хатын - кызларның барысын бергә җыйсак... Беләсезме, күпме булыр иде алар? 38 ел эшләү дәверендә күпме үлчәү үлчәнгән дә күпме кием җөйләнгән! Хәзер инде ул бу һөнәр яшьтән аңа насыйп булган дип кистереп әйтә ала. Норлат шәһәренен Октябрьская урамында кечкенә генә йорт. Иртә атасыз калган гаиләдә гел җитмәүчелек. Әнисе, өлкән бала Тамарадан тыш өйдә бит әле әбисе, туганнан - туган апалары, ике сеңлесе, энесе бар. Шуңа да эшкә дә 8не бетерүгә, 16 яшеннән китте. Нишләсен? Әнисе Анна Игнатьевна кулларыннан һәрчак җылы ипи исе килсә дә - ул ипи пешерүче булып эшли иде - сугыштан соңгы ул елларда тамак гел тук түгел иде шул әле. Тамара тышкы өс киемнәре тегүче Чапаев исемендәге артельгә урнашты. Энә белән эш итә белсә дә, беренче остазы сүзеннән һичкайчан баш тартканы булмады: җинне ничек итеп дөрес утыртырга, җөйне ничек тигез салырга... Ул вакытта әле үтүкнең дә күмер белән җылытыла торганын куллана иделәр, әйберне үтүкләп бетергәнче, кулың өзелеп төшәрлек, эшкә соңга кала күрмә - дисциплина мәсьәләсе бик кырыс иде. Аның тыйнак хезмәт хакы гаилә өчен зур терәк саналды, аны алмас борын тиенен тиенгә бүлеп тә куялар иде. Шулай 10 ел узды. Артель каршында җинел киемнәр тегү цехы ачылгач, Владимир Устинович Акмурзин Тамараны (ул инде Ямкина иде) курсларга җибәрде. Улы Олег үсеп - тернәкләнеп килә иде. 9 ай дәвамында ул күп нәрсәгә өйрәнергә тырышты. Шуннан бирле һич аерылгысыз булып ательеда эшли. Әйтерсең, беренче җөе белән үзен шул һөнәргә беркетеп куйды. Гомер дигәнең тиз үтә икән. Яхшысы да, яманы да басыла, кичерелә. Әмма Тамара Петровнаның гаҗәеп бер сыйфаты бар: ул һәрчак сабыр, игелекле. Тыныч һәм итагатьле. Кешеләргә хөрмәт белән карый белә. Инде тормышында ниндидер кәефсезлек бар икән, аны һич эштә, кешеләр белән мөнәсәбәттә чагылдырмаска тырыша. Ул күңелсезлек эш бусагасының теге ягында калырга тиеш. Ә син - кызларга елмай, заказчыны хөрмәт ит. Җинел түгелдер, әмма башкача мөмкин түгел - кешеләр белән эш итәсең.

Бүген аның бригадасында өчәү эшлиләр: Наталья Александрова - бригадир, Сания апа Сафиуллова һәм Җәмилә Садыйкова. Алар зур стажлы, тәҗрибәле тегүчеләр. Сөйләшкәндә 10 - 15 ел элек ничек эшләүләрен искә алдылар. Җинел киемнәр тегү буенча 4 бригада 2 сменада эшли иде, алай да заказларны срогында өлгертеп бирү кыен иде. Итәкләр, блузкалар, күлмәкләр. Тамара Петровнаның 15 - 20шәр заказ кабул иткән көннәре бар иде, ә хәзер бер заказ кермәгән көннәр дә бар. Нишлисең - базар! Юкса, Тамара Петровна заманында нинди генә материалдан, нинди генә катлаулы фасоннар белән тегәргә алынмый иде. Хәзер заказ булмаганда кызлар халатлар тегәләр, хатын - кызларга анысы да бик кирәк. Тегүчеләрнең хезмәт хакы бүгенге чорда бик тыйнак булса да, күңелләрен сүрелдермичә эшләрен дәвам итәләр. Үзләре исә «Надежда» предприятиесенә хатын - кыз өметләрен дә җуймыйлар: яшисе, яхшы заманнар җиткәнче сакланасы иде. Юкса, кайбер районнарда ательеларны күптәннән яптылар. Шуңа да кызлар һәр кечкенә генә үзгәрештән дә яхшылык көтәләр: менә җәй җитә, ходай кушса, заказлар булмасмы. Ул чакта Тамара Петровна Ямкинага бүләккә бирелгән шкатулка да ешрак кирәгер, анда бит аның эш кораллары - уймак, энәләр, акбур, метр саклана.

Соңыннан сүз бәйрәм темасына күчте.

- Сеңелләрем Клава, Лида, энем Владимир белән бергә әниебез янына чәйгә җыелабыз. Аны бәйрәм белән котлыйбыз. Хатын - кызны, әни кешене ул бәхеттән мәхрүм итү һич ярамый...- ди ул.

***

Эш сәгате бетәр алдыннан гына ательега заказчы килде. Трикотин алып килгән. Танышып киттек. Норлатта күптән түгел генә икән. Ательеда өченче тапкыр тектерә. «Беләсезме, базарда һич үземә ошаган кием сайлый алмыйм. Биредә ичмаса җаным теләгәнне тегәләр».

Т.НАЗАРОВА.

## «СӨЕНДЕРЕП КЕНӘ ТОРСАК ИДЕ...»



Шәһәр - төнге йокыда. Үзәк телеграфта да тәүлекнең башка вакытларындагыдан тынычрак бу минутларда. Бер көйгә генә теркелдәп утырган телеграф аппараты гына ерак араларга бәйрәм котлаулары һәм теләкләре, сәламәтлек һәм бәхет, тынычлык һәм озын гомер теләгән өзек - өзек җөмләләр юллый. Биредә үз вазифаларын нечкәлекләренә кадәр белгән, егермешәр еллык тәҗрибәгә ия кызлар эшли. Барысы да диярлек хезмәт юлларын заманында телеграммалар ташудан башлаган. Ә инде бирегә эшкә килгәч беренче һөнәри күнекмәләрне шушы участокның ветераннары Зоя Семеновна Тимофеева белән Клавдия Никитична Ивановадан алганнар.

Телеграфта, телеграмма ташучылардан кала барысы да - хатын - кызлар: Людмила Алипова, Светлана Мөхәммәтҗанова, Капитолина Демидова, Екатерина Прокопьева, Ирина Кулагина һәм башкалар.

- Коллективыбыз дус һәм бердәм,- ди Гөлчәчәк Хәсәнова. - Телеграфчы иң элек җыйнак һәм игътибарлы булырга тиеш: без кәгазьгә төшерелгән сүзләр белән эш итсәк тә, ул юллар артында кеше язмышы икәнлеген онытырга хакыбыз юк. Телеграммаларны Россия буйлап кына түгел, БДБ илләренә дә, ерак чит дәүләтләргә дә җибәрәләр - Германия, Франция, Польшага, мәсәлән.

Гөлчәчәк хезмәттәшләре арасыннан Тамара Майор турында аерым әйтте. Эшен белеп, пөхтәлек белән эшли, аңа бик җаваплы карый. Аннары, һәр коллективта, бигрәк тә хатын - кызлардан торганында әһәмиятле булган сабырлыкка ия.

Әнә Тамараның бармаклары телеграф аппаратының клавишлары буйлап бии һәм шатлык хисләрен дә, еш кына кайгы хәбәрен дә үзенә сыйдырган телеграммалар ерак - еракларга китә... Гел сөенечле хәбәрләр генә тапшырып торырлар иде дә бит ул кызлар...

**Рәсемдә: район элемтә бүлеге телеграфчысы Тамара Майор.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**



## Җырларының тагын да матуры алда әле

Халык җырлары. Аларда халыкның тарихы да, мәдәнияты да, гасырлардан килә торган традицияләре һәм гореф - гадәтләре дә чагылыш таба. Аларны без кайгы килгән чакларда да, шатлыктан да җырлыйбыз, алар безгә тормышыбызны гүзәллек кануннарына туры китереп корырга да булыша. «Родник» чуваш халык җыр ансамбле солисты Надежда Митянина да җырга гашыйк. Үзешчән артистлар башкарган моңлы да, дәртле дә җырлар кешеләрнең күңелен күтәрә, аларны тагын да рәхимлерәк итә. Надежда Митянина ансамбль белән бергә Октябрь һәм башка районнарның күп кенә сәхнәләрендә концертларда катнаша, Татарстан һәм күрше Самара өлкәсе шәһәрләрендә дә чыгыш ясый. Әле менә хатын - кызлар бәйрәме алдыннан гына ансамбль «Чуваш сандугачы - 97» республика җыр фестивалендә уңышлы чыгыш ясап, лауреат исемен алды.

Бу коллективның җырлыйсы җырлары алда да күп әле.

**Рәсемдә: «Родник» чуваш җыры ансамбле солисты Надежда Митянина район мәдәният йорты сәхнәсендә.**

Н.АЗИЗОВ фотосы.

## КОТЛЫЙБЫЗ!



Югары Норлат авылында яшәүче кадерле әткәебез **Рифкать Исмәгыйль** улы һәм әнкәебез **Нурания Әбрар** кызы **МИФТАХОВЛАРНЫҢ**, бергә яшәүләренә 12 мартта 25 ел тула. Без аларны көмеш туйлары белән чын күңелдән котлыйбыз. Туачак көннәрегез кайгы - хәсрәтсез үтсен, безне тапкан, баккан, кадерләп үстергән, тәрбияләп кеше иткән өчен мең рәхмәт сезгә. Гомерегез озын, тигез, алдагы көннәрегез тыныч, бәхетле булсын. Озак - озак итеп безгә сөенеч булып яшәвегезне телибез.

**Изге теләкләр белән балаларыгыз, киявегез, киленегез һәм оныкларыгыз.**

## Һәр ир - ат көнләшерлекләр



Хатын - кызлар һәр нәрсәне булдыра, дип юкка әйтмиләрдер, мөгаен. Әйе, бу турыда кистереп әйтеп була.. Әнә, Светлана Владимировна Андреевага карагыз. Беренче карашка бик нечкә, тыныч, гади күренә ул. Ә эше буенча фикер йөртсәң... Урта Камышлы балалар яслесендә ул башкарган эш теләсә нинди ир - атның да хәленнән килми әле. Тыныч холыклы бу хатын - кыз районда беренчеләрдән булып, үзе җитәкчелек итә торган учреждениедә газлаштыру эшен тәмамлады. Районда үз - үзләрен яшелчә, җиләк - җимеш белән тәэмин итүче аз санлы ясленәрнең берсе дә - Урта Камышлыныкы. Биредә тәрбия эше дә яхшы куелган. Коллектив та бердәм, максатчан. Билгеле инде, бу күркәм эшләрнең башында аның җитәкчесе Светлана Андреева тора.

Авыл урта мәктәбендә дә менә дигән укытучылар бар. Марина Александровна белән Лилия Леонидовна, мәсәлән, чагыштырмача яшь педагоглар булсалар да, тәҗрибәлеләрдән һич калышмыйча эшлиләр. Икесе дә махсус урта белемгә ия, икесе дә читтән торып институтта укыйлар. Марина Кириллова башлангыч классларга белем бирсә, Лилия Сидорова рус теле һәм әдәбияты укыта. Икенчесен мәктәптә икенче ел эшләгәндә үк аны мәктәп директорының оештыру - тәрбия эшләре буенча урынбасары итеп билгеләделәр. Хәзер ул аерым бер класс өчен генә түгел, ә тулаем бер мәктәптә балаларның класстан тыш вакытын үткәрү өчен җаваплы. Лилия Леонидовна исә моның өчен бөтен тырышлыгын куя: балалар өчен традицион булмаган чаралар үткәрә, тәҗрибәле оештыручыларның эш алымнарын өйрәнә.

- Кызлар бик әйбәт эшлиләр. Җитезлекләре, эштәге ныклыкларына теләсә нинди ир - ат көнләшерлек,- ди алар турында Урта Камышлы урта мәктәбе директоры В.Захарова да.

**Рәсемдә: С.Андреева, М.Кириллова, Л.Сидорова.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# КҮҢЕЛЕНӘ КҮРӘ КӨН КҮРӘ

( Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Болардан тыш, авыл клубында, мәктәптә узган бер генә чара аның катнашыннан башка үттеме икән? Мәктәптә яшүсмер кызлар, малайлар белән «серле» әңгәмәләр алып баручы буларак та исләрендә калдырдылар аны укучылар. Прививкаларны да ул ясый иде. Халык арасында профилактик эш алып баруны да онытмады. Авыл хатын - кызлар советын кем җитәкләде, иптәшләр судының хөкемдарлар өстәле артында утыручыларның берсе кем дип сорагыз. Кызыл Хач җәмгыяте башында кем торды? Донорлык хәрәкәтен кем оештырды? Рушания Салиховна, билгеле. 1968 нче елда Октябрь районы Татарстан Республикасы күләмендә донорлык буенча I урын алгач, пункт мөдире Хәниеваны, районнан тагын 3 кешене «Санитария оборонасы отличнигы» билгесе тапшыру өчен Мәскәүгә чакырганнар иде хәтта. Менә шулай, кем әйтмешли, көпчәккә эләккән тиендәй булып, гомер үткәнен дә сизми калдылар. Ире Йосыфхан да гел эштә булды. Партия оешмасын җитәкләде, профсоюз лидеры булды. Дөнья, эш мәшәкатьләре арасында балаларының үсеп, буй җитүләрен дә сизми калды ата белән ана кеше. Гел генә эш, җәмәгать мәшәкатьләре белән мәшгуль әниләрен өйдә ял иттерергә теләп, яшьли өй, йорт эшләрен караштыра торган булдылар алар. Хәзер инде үзләре әни, әти булдылар. Олы кызлары Рузалия әнисе юлыннан китте: Казанда медицина институтын тәмамлады, хәзер Йошкар - Олада табиб, Илһамы Казан авыл хуҗалыгы институтын сайлады. Хәзер районның «Чирмешән» КХАсын җитәкли. Яраталар, үз итәләр аны авылда. Икесенең дә гаиләләре, икешәр балалары бар. Кечеләре Ралия дә - югары уку йортын тәмамлады, филолог, Норлатта 4 нче мәктәптә укыта. Хәзер Йосыфхан Миннеханович белән Рушания Сәлиховна төп йортта бер үзләре генә яшәп яталар. Бер үзләре саналалар гына инде. Хәниевлар йортыннан кеше бер дә өзелми: әле күршеләре йомышка керәләр, әле ярдәм сорап, әле киңәш... Әле балалары кайтып төшә. Атна азагында Ралияләре кайтып җитә.

- Хатын - кыз никадәр генә көчле рухлы булса да, ир - ат аның төп терәге. Йосыфханым белән тигез килеш картаерга язсын инде, йорт буенча бөтен эшне ул үз җилкәсенә алмаса, бу яшемә тикле яраткан хезмәтемне башкара да алмаган булыр идем,- ди Рушания апа һәм Йосыфханына карап өстәп куя, - картаймавымның да бөтен сере Йосыфхан белән бәйле...

Һәм, һәрвакыттагыча болай да очкынлы күзләре белән нур чәчеп, чын күңеленнән шаркылдап көлеп җибәрә. Бу вакытта аның болай да ягымлы йөзе тагын да ялтырый, матураеп китә. Үзен тормышта чын - чынлап бәхетле санап, аннан ямь табып яшәгән кеше генә шундый буладыр, мөгаен.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# Катяның тәүге йолдызы



Катя Сайбаталовага сигез генә яшь һәм аның бар гомере - яшьлеге дә, яңадан - яңа очрашулары, яулыйсы уңышлары да алда әле. Әмма үзенең тәүге йолдыз сәгатен - «Дюймовочка - 95» шәһәр конкурсындагы уңышлы дебюты һәм җинүче исемен алуын гомер буена исендә калдырыр ул.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# ТУЙЛАР ничә була?



***Гомернең өч туе була: кеше дөньяга аваз сала, гаилә кора, якты дөнья белән хушлаша... Алай гына түгел икән бит! Чәчләр - чәчкә бәйләнгәч тә, гаилә тормышын яңа туйлар бизи икән.***

Никахлашу көнен **яшел** туй дип әйтү дөрес булыр. Ә инде бер елдан **ситсы (марля)** туй. Моны өйләнешүчеләрнең гадәти тормышка күчүеннән, ситсы кебек гадилектән чыгып шулай әйтәләр. Гаиләнең биш еллык гомерен - **агач** туй белән билгеләп үткәннәр. Бу көнне гадәттә ир белән хатын бер - берсенә агачтан бизәп эшләнгән әйберләр бүләк итәләр. Җиде елдан - **роза** туй. Бу мәҗлескә никах туенда катнашкан кешеләр чакырыла. Ире хатынына роза чәчәкләре бүләк итә. Розалар алсу төстә булырга тиеш.

Бергә - бергә 15 ел гомер иткәч, гаиләне **пыяла** туй көтә. Ир белән хатын арасында мөнәсәбәтләр пыяладай керсез, саф булсын дип, туйда пыяла әйберләр бүләк ителә.

Егерме елдан - **фарфор** туй. Бәйрәм табынына фарфор кәсәләр куела. Ләкин ул кем исәбенә алына? Бу мәсьәләдә фикерләр аерыла. Берәүләр, яңа сервизны гаилә үзе сатып ала, чөнки бу чорда инде гаилә шактый тернәкләнгән була, дисә, икенчеләр, яңа сервизны кунаклар бүләк итә, дигән фикердә кала.

Егерме биш елдан - **көмеш** туй. Утыз ел - **энҗе** туй. Утыз ел бергә яшәү чорында ир белән хатын энҗеләрдән төймә тезгәндәй була. Ир тормыш иптәшенә энҗе тезмәле муенса бүләк итәргә тиеш. Әгәр инде гомер юлыннан утыз биш ел бергә атласалар, гаиләне **җитен** туй көтәчәк. Бу туйда **җитен** көнкүреш әйберләре бүләк итәләр. Алар гаилә тормышының соңгы көннәренәчә хезмәт итәргә тиеш.

Кырык елдан - **якут** туй. Йөзекләрнең кашы кызыл якутка алышына, яки балдакка мәхәббәт таҗы куела.

Илле елдан - **алтын** туй! Бу көнне балдаклар алмашына. Бер - беренә алтын әйбер бүләк итү гадәткә кергән.

Алтмыш елдан - **бриллиант (алмаз)**, җитмеш биш елдан - **таҗлы** туй. Сәламәтлек, тигез гомер белән барыгызга да таҗлы туйларыгызны каршыларга насыйп булсын!

## Котлыйбыз



Югары Норлат авылында яшәүче кадерле әтиебез **Габбас Әхмәткәрим улы Нуретдиновны** туган көне белән котлыйбыз. Озын гомер, нык исәнлек, бәхетле картлык, әни белән тигез гомер итүеңне телибез.

Котлап сине туган көнең белән

Без телибез сиңа ак бәхет.

Киләчәгең якты, матур булсын,

Шатлык юлдаш булсын һәрвакыт.

**Изге теләкләр белән улың Газинур, киленең Фәридә, оныкларың Ильмир, Әлфирә.**

# ТЫШТАН ГЫНА ШУНДЫЙ УЛ



Дәүләт автоинспекциясе бүлегендә халыкның һичкайчан бетеп торганы юк: берәүләренә белешмә кирәк, икенчеләрен аңлашылмаучылык китергән бирегә, өченчеләре... Аларның һәркайсы иң элек кабул итү бүлмәсенә керә. Бирегә аларны беренче карашка аз сүзле, елмаюга бик саран Нурзия атлы кыз каршы ала. Әмма үзе һәркемнең үтенечен игътибар белән тыңлый ул, теләүчеләргә ярдәм күрсәтә, бу эш мөмкин булмаганда, кайда мөрәҗәгать итәргә икәнлеген аңлата.

Бүлек хезмәткәрләре дә бу бүлмәдә еш булалар. Алар конкрет эш белән керәләр бирегә: хуҗасы Нурзия булган акыллы машина - компьютер сиңа санаулы минут эчендә юл - транспорт мәсьәләләренә кагылышлы теләсә нинди информацияне бирә.

Нурзия Вәлиевна Ибәтуллина биредә биш еллап эшли. Инде ул үз эшен күп нечкәлекләренә кадәр үзләштерде. Документлар тутыру, рәсмиләштерү эшен дә җиренә җиткереп башкара. Тиз арада катлаулы техника - компьютерны да үзләштерде.

Сүзгә, елмаюга юмарт булмаса да, Нурзияне якыннан белгән кешеләр аның киң күңеллелеген, һәрчак ярдәмгә килергә әзер торуын югары бәялиләр.

**Рәсемдә: Н.ИБӘТУЛЛИНА.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**


## Белдерүләр

**Идел Буе региональ наркология үзәге**

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көнне, 14 мартта көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

**«Жилстрой» АҖ акционерларының гомуми җыелышы карары белән җәмгыятьнең 53 нче СМУ структур подразделениесе бетерелә.**

Дәгъвалар 1997 елның 15 апреленә кадәр кабул ителә.

**Сатабыз**

**Шәһәр эчендә бакча участогы.** Тел.: 5 - 17 - 66 (кичке 6дан соң).

***

**76 миллиметрлы җылылык торбалары.** Салдакайда Хәмидуллинга мөрәҗәгать итәргә.

***

**1995 елгы, 022203 км. йөргән ВАЗ - 21213.** Тел.: 5 - 11 - 34.

***

**Ашыгыч төстә 1983 елгы, әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21013.** Тел.: 2 - 22 - 70 (кичке 5тән соң).

**Сатабыз яки алмаштырабыз**

**Газ плитәсе һәм баян сатыла. Баянын гармунга да алыштырып була**. Тел.: 5 - 21 - 94.


**Газетабызның киләсе саны 12 мартта чыга.**


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2083 данә. Заказ N 6035.